Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

**КАРАР № 2-1**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 6 октябре

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2018 елның елның 10 маендагы 7-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең, даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәтенә түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, социаль гарантияләрне, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләрнең, даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсенә, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 26 маддәсенә, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы, “Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында”

2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы, “Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2006 елның 10 нчы июлендәге 353 номерлы, “Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында” 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2018 елның елның 10 маендагы 7-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р.Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге
Советының 2020 елның 6 октябре
2-1 номерлы карарына
кушымта

“Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге
Советының 2018 елның 10 маендагы
7-1 номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәре

| N п/п | Вазыйфаның аталышы | Вазыйфаи оклад, сумнар |
|---|---|---|
| | | 10 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 18742 |
| 2. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 18397 |
| 3. | Бүлек башлыгы | 15177 |
| 4. | Әйдәүче белгеч | 12763 |

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен тәгаенләү өчен, тиңдәшле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен хезмәткә түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.

Күрсәтелгән күрсәткечләргә карап, “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге (5 мең кешедән 10 мең кешегә кадәр) унынчы төркемгә кертелгән.”